**Республика Татарстан**
**Альметьевское сельское**
**поселение Сармановского**
**муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль районы**
**Әлмәт авыл җирлеге**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

**БОЕРЫК**

27 апрель 2018 ел

**№ 5**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге белгеченең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 30 мартындагы 195 номерлы "Татарстан Республикасы Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында" карары, Сарман муниципаль районы Советының 2018 елның 4 апрелендәге 116 номерлы " Татарстан Республикасы Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында карары нигезендә" Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге белгеченә хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәне расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында игълан итәргә (pravo.tatarstan.ru), шулай ук Сарман муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http:/ www.sarmanovo.tatar.ru веб адресы буенча урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми халыкка игълан ителгән мизгелдән үз көченә керә һәм 2018 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Әлмәт авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе — Д. Ә. Газизов